**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**31 март, 2022 ел** **№ 158**

**Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 139 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 139 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Биектау муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә» «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары» дип аталган түбәндәге эчтәлекле 7 бүлекне өстәргә:

7. **Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Якын территориядә яисә гомуми файдаланудагы башка территорияләрдә чүп-чар һәм җитештерү һәм куллану калдыкларының булуы.

2. Якын территориядә карантин, агулы һәм чүп үләннәре, агач һәм куакларны кисүдән калдыклар булуы.

3. Торак булмаган биналар, төзелмәләр, корылмалар фасадларында, башка биналар, төзелмәләр, корылмалар диварларында, шулай ук төзекләндерүнең башка элементларында һәм җәмәгать урыннарында үз белдеге белән ясалган язулар яисә рәсемнәр булу.

4. Якын-тирәдәге территорияләрдә гражданнарның иркле һәм куркынычсыз үтүенә киртә булган боз катламнары булу.

5. Биналар, корылмалар түбәләрендә боз сөңгеләре булу.

6. Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт, халыкка социаль хезмәт күрсәтү объектларына халыкның аз мобильле төркемнәре ирекле керүгә киртәләр булу.

7. Инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус тамгаларны, язуларны юк итү яки зарарлау.

8. Җир эшләрен аларны гамәлгә ашыруга рөхсәттән башка йә мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын арттырып гамәлгә ашыру.

9. Җир эшләрен башкарганда, биналарга һәм аларга керү юлларына ирекле керүгә, шулай ук ишегалларына ирекле керүгә, җәяүлеләрнең куркынычсызлыгын һәм җәяүлеләрнең, инвалидларны һәм халыкның башка аз мобильле төркемнәрен дә кертеп, куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итүгә тоткарлыклар тудыру.

10. Төзекләндерү кагыйдәләре белән аларда транспорт чараларын урнаштыру чикләнгән газонда яисә башка яшелләндерелгән, яисә рекреация территориясендә транспорт чараларын урнаштыру.

11. Юк итү (алып ташлау) яисә күчереп утырту бары тик шундый документлар нигезендә генә башкарылырга тиеш булган очракларда, кисү өчен билет алмыйча яисә агач һәм куакларны күчереп утыртуга рөхсәт алмыйча, агач һәм куакларны юк итү (алып ташлау), күчереп утырту.

12. Гомуми файдаланудагы территорияләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын чыгарып йөртү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http:pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет рәисе урынбасары,
район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров